**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлегенең Үрнәк-Кумәк торак пунктында гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

2023 елның 18 ноябре №2

**2023 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Глазово авыл җирлегенең Үрнәк-Кумәк торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турында**

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлеге Үрнәк-Кумәк торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2024елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Глазово авыл җирлеге Үрнәк-Кумәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, ялгыз яшәүче өлкәннәрдән тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 (Биш йөз) сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

1) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә ирешү мөмкинлеген тәэмин итү таләпләрен үтәү, җирлек территориясен төзекләндерүне күрсәтелгән кагыйдәләргә ярашлы оештыру, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру:
- урам яктырткычларына техник хезмәт күрсәтүҮрнәк-Кумәк авылы
2) торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- юлларны чокырлы ремонтлау: Мәктәп урамы;
- юлларны кардан чистарту: Лесная,Садовая, Мәктәп, Строительная, Дуслык урамнары.

3) торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:
-порывларны бетерү;

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Үрнәк-Кумәк авылы, Мәктәп урамы, 3а йорт, Глазово авылы, Заречная урамы, 13, Петропавловка авылы, Горький урамы, 19а адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) кабул ителгәнннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
“Глазово авыл җирлеге”
муниципаль берәмлеге
башлыгы Н.К.Карабаева